| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Кудашевского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Кодаш авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

07.02.2020 Кодаш авылы № 56-1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының "Кодаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Әгерҗе районы прокуратурасының 2020 елның 20 гыйнварыннан 02-08-01/33 номерлы «Кодаш авыл җирлеге Уставының аерым нигезләмәләренә карата протесты»н үтәү йөзеннән, «Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының "Кодаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге Советы **К А Р А Р  И Т ТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проектын беренче укылышта кабул итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында http://agryz.tatarstan.ru веб-адресы буенча; Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Түбәндәге составта карар проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем төзергә:

Шакиров Ф.М. – Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге Советы Рәисе, Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге башлыгы;

Салахиев Ф.М.– Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге депутаты;

Закирова А.Н. – Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге

депутаты;

Трефилова С.И. – Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге депутаты;

Шакиров Ф.Ф. – Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге депутаты.

4. Әлеге карарның ачык тыңлауларын 2020 елның 17 февралендә сәгать 10:00да Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге Кодаш авыл клубы бинасында үткәрергә.

5. Эшче төркемгә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проектына карата Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге Советы депутатлары һәм гражданнарның тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге Советына карауга чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны карар проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркемгә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Ф.М.ШАКИРОВ

АГРЫЗСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Совет
Кудашевского
сельского поселения
Кодаш авыл
җирлеге Советы
ИНН 1601002501
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Кодаш авыл җирлеге Советының
07.02.2020 № 56-1
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты**

**29нчы статьяның 7нче өлешен яңа редакциядә бәян итәргә:**

«7. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатлар хокуклы түгел:

«1) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;

2) коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы тарафыннан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында (конференция) түләүсез катнашу;

б) коммерцияле булмаган оешма белән түләүсез идарә итүдә (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында (конференция) катнашудан тыш), Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртиптә яллаучы вәкиле рөхсәте белән катнашу;

в) Россия Федерациясе субъектының муниципаль берәмлекләре советында, башка муниципаль берәмлекләрнең берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г) муниципаль берәмлек исеменнән, муниципаль хокукый актлар яки муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында өлешләр) белән идарә итү тәртибе нигезендә муниципаль берәмлекне гамәлгә куючы (акционер, анда катнашучы), оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләүче булган идарә органнарында һәм оешманың ревизия комиссиясендә, муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен яклау;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар,

3) башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә, мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш. Шул ук вакытта мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек бары тик чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Кодаш авыл җирлеге Советының
07.02.2020 № 56-1
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты**

**29нчы статьяның 7нче өлешен яңа редакциядә бәян итәргә:**

«7. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатлар хокуклы түгел:

«1) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;

2) коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы тарафыннан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында (конференция) түләүсез катнашу;

б) коммерцияле булмаган оешма белән түләүсез идарә итүдә (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында (конференция) катнашудан тыш), Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртиптә яллаучы вәкиле рөхсәте белән катнашу;

в) Россия Федерациясе субъектының муниципаль берәмлекләре советында, башка муниципаль берәмлекләрнең берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г) муниципаль берәмлек исеменнән, муниципаль хокукый актлар яки муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында өлешләр) белән идарә итү тәртибе нигезендә муниципаль берәмлекне гамәлгә куючы (акционер, анда катнашучы), оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләүче булган идарә органнарында һәм оешманың ревизия комиссиясендә, муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен яклау;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар,

3) башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә, мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш. Шул ук вакытта мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек бары тик чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит